| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.06.2026 ел Баулы шәһәре №74

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге 124 номерлы карары белән расланган, реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 333.33 һәм 333.35 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 2026 елның 25 маендагы 142-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге 124 номерлы карары белән расланган, реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең (2022 елның 29 июлендәге 162 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегендә:

2.9. Пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.9. Мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме
Хезмәт күрсәтүләр һәм аны алу ысуллары

«2.9.1. Дәүләт пошлинасы Россия Федерациясе Салым кодексының 333.33 статьясындагы 1 өлешенең 105 пунктында түбәндәге күләмдә каралган:

реклама конструкциясен урнаштыруга рөхсәт биргән өчен - 10 000 сум.

Дәүләт пошлинасы мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза биргәнче түләнә.

2.9.2. Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәтне гамәлдән чыгару хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

Хезмәт күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын түләү мөрәҗәгать итүче тарафыннан алдан тутырылган реквизитлар буенча республика порталыннан файдаланып башкарылырга мөмкин.

Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын түләгәндә мөрәҗәгать итүчегә тутырылган яисә өлешчә тутырылган түләү документын саклап калу, шулай ук тутырылган түләү документының күчермәсен кәгазьдә бастыру мөмкинлеге тәэмин ителә.

Түләү документында исәпләүнең уникаль идентификаторы һәм түләүченең идентификаторы күрсәтелә.

Мөрәҗәгать итүчегә республика порталы аша хезмәт күрсәткән өчен дәүләт пошлинасы факты турында хәбәр ителә.

2.9.3. Башкарма комитет мөрәҗәгать итүчедән мөрәҗәгать итүченең Хезмәт күрсәтү өчен түләү кертүен раслый торган документлар күрсәтүне таләп итәргә хокуклы түгел.

Хезмәт күрсәтү өчен дәүләт пошлинасын түләү турында мәгълүмат, әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса, дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат системасындагы мәгълүматтан файдаланып бирелә.

2.9.4. Дәүләт пошлинасы яисә хезмәт күрсәтү өчен алына торган башка түләү күләме турындагы мәгълүмат Бердәм, Республика порталларында урнаштырыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров